**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2022 елның «8» апреленнән № 20-153

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларга, контроль-хисап органы рәисенә акчалата бүләкләүләр, Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 12 апрелендәге 35-197 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәисләре, аудиторлары, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары белән расланган «Җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 13 декабрендәге 1222 номерлы карары нигезендәТатарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларга, контроль-хисап органы рәисенә акчалата бүләкләүләр, Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 12 апрелендәге 35-197 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2018 елның 26 июнендәге 39-218 номерлы, 2018 елның 8 ноябрендәге 42-245 номерлы, 2020 елның 29 апрелендәге 60-375 номерлы, 2020 елның 04 сентябрендәге 63-398 номерлы, 2020 елның 3 ноябрендәге 2-12 номерлы, 2020 елның 8 декабрендәге 3-21 номерлы, 2021 елның 17 августындагы 12-96 номерлы, 2021 елның 09 декабрендәге 16-127 номерлы карларындагы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.«Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль берәмлегендә һәм авыл җирлекләрендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-исәп органы рәисенең, рәис урынбасарының, аудиторның айлык акчалата түләүләре» сүзләреннән соң «нормага салынмаган хезмәт көне шартларында

эшләгән өчен айлык компенсация түләүләренә, муниципаль хезмәткәрләргә айлык акчалата түләүләргә , аларның төп вазифаларына хокукый актларга һәм хокукый актлар проектларына хокукый экспертиза үткәрү, хокукый актлар проектларын әзерләү һәм редакцияләү һәм аларны югары юридик белемгә ия булган юрист яки башкаручы сыйфатында визалау (юридик эш өчен өстәмә), профильле фәнни дәрәҗә өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү кертү кирә» сүзләрен өстәргә;

1.2. 4 нче кушымтаның 1 абзацында «(кыенлык, киеренкелек, хезмәттәге югары казанышлар, махсус эш режимы)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. Әлеге карарның 6 нчы кушымтасы булган «Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә айлык акчалата бүләкләү күләме һәм аны гамәлгә ашыру тәртибе»н кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

1.4. Әлеге карарның 10 нчы кушымтасы булган «Төп хезмәт вазыйфаларына хокукый актларга һәм хокукый актлар проектларына хокукый экспертиза үткәрү, хокукый актлар проектларын әзерләү һәм редакцияләү, югары юридик белеме булган юрист яки башкаручы сыйфатында визалау (юридик эш өчен өстәмәләр) кергән муниципаль хезмәткәрләргә айлык түләүне гамәлгә ашыру күләмнәре һәм тәртибе»н кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

1.5. 11 нче кушымтаның 1 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә;

«1. Нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен айлык компенсация түләве вазыйфаи окладның 2 процентыннан артмаган күләмдә билгеләнә.

1.6. 12 нче кушымтаның 2 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә;

«2. Вазыйфаи окладка айлык өстәмә:

фән кандидатының профильле гыйльми дәрәҗәсе өчен - вазыйфаи окладның 1,5 процентыннан артмаган күләмдә;

фәннәр докторының профильле гыйльми дәрәҗәсе өчен-вазыйфаи окладның 2 процентыннан артмаган күләмдә.»;

1.7. 17 нче кушымтаның1 нче пунктының 2 пунктчасында «(кыенлык, киеренкелек, хезмәттәге югары казанышлар, махсус эш режимы)» сүзләрен төшереп калдырырга.

- түбәндәге эчтәлекле 7 пункт белән тулыландырырга:

«7) нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен айлык компенсация түләүләре, юридик эш өчен өстәмә түләүләр һәм профильле гыйльми дәрәҗә өчен айлык хезмәт хакына айлык өстәмә түләү - вазыйфаи окладларның 2,5 процентыннан артмаган күләмдә.».

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә;

әлеге карарның 2 пунктының гамәлдә булуы 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http:/ / pravo. tatarstan. ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Советының
2018 елның 12 апрелендәге
35-197 номерлы карарына
6 нчы кушымта
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Советының
2022 елның 8 апрелендәге
20-153 номерлы карары
редакциясендә)

Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә айлык акчалата бүләкләрнең күләме һәм аны гамәлгә ашыру тәртибе

Муниципаль хезмәткәргә вазыйфаи окладның 1 процентыннан артмаган күләмдә ай саен акчалата бүләкләү билгеләнә, моңа муниципаль хезмәткәрнең җирле үзидарә органнары структурасы стандартларын муниципаль хезмәт вазыйфасына азрак вазыйфаи оклады белән билгән муниципаль хезмәт вазыйфасына кертү белән бәйле рәвештә җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртеп корганда билгеләнү очрагы керми, ул элек биләгән хезмәт хакы белән чагыштырганда, муниципаль хезмәткәрнең акчалата түләү күләмен элек биләгән вазыйфа буенча акчалата түләү күләменә җиткерүне исәпкә алып башкарыла.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Советының
2018 елның 12 апрелендәге
35-197 номерлы карарына
10 нчы кушымта
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Советының
2022 елның 8 апрелендәге
20-153 номерлы карары
редакциясендә)

Төп хезмәт вазыйфаларына хокукый актларга хокукый экспертиза үткәрү, хокукый актлар проектларын әзерләү һәм редакцияләү, югары юридик белемгә ия булган юрист яки башкаручы сыйфатында визалау (юридик эш өчен өстәмә)кергән муниципаль хезмәткәрләргә айлык түләүне гамәлгә ашыру күләмнәре һәм тәртибе

Төп хезмәт вазыйфаларына хокукый актларга һәм хокукый актлар проектларына хокукый экспертиза үткәрү, хокукый актлар проектларын әзерләү һәм редакцияләү, югары юридик белемгә ия булган юрист яки башкаручы сыйфатында визалау (юридик эш өчен өстәмә) керә торган муниципаль хезмәткәрләргә айлык түләү (юридик эш өчен өстәмә), түбәндәгедән артмаган күләмнәрдә:

| Муниципаль хезмәт вазыйфалары | Күләме юридик эшләр өчен вазыйфаи окладка өстәмә түләү, процентларда |
|---|---|
| Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары | 8 |
| Муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары | 6 |
| Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфалары | 4 |
| Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары | 2 |